ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10.03.2017 Казан ш. № 10-2/кс

2017 елга «Татэнерго» акционерлык җәмгыятенең Чаллы ТЭЦ филиалы өчен салкын суны транспортлаганга һәм җыентык суларны транспортлаганга тарифлар билгеләү хакында

«Су белән тәэмин итү һәм су бүлү турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә бәя хасил итү турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә җайга салынулы бәяләрне (тарифларны) хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Салкын су белән тәэмин итүне һәм су бүлүне гамәлгә ашыручы «Татэнерго» акционерлык җәмгыятенең Чаллы ТЭЦ филиалы өчен салкын суны транспортлаганга һәм җыентык суларны транспортлаганга шушы карар кушымтасы нигезендә, календарь буенча бүлеп, тарифлар билгеләргә.

2. Бу карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар карар үз көченә кергәннән башлап 2017 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә булачак.

3. Салкын су белән тәэмин итүне һәм су бүлүне гамәлгә ашыручы «Татэнерго» акционерлык җәмгыятенең Чаллы ТЭЦ филиалына Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы 6 номерлы карары белән расланган су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартларына туры китереп, ирекле файдаланылырга тиешле мәгълүматны чираттагы җайга салу

чорына тарифлар билгеләү турындагы карар кабул ителгән көннән башлап 30 календарь көненнән соңга калмыйча ачарга.

4. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисе М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт комитетының
10.03.2017 № 10-2/кс карарына кушымта

Салкын су белән тәэмин итүне һәм су бүлүне гамәлгә ашыручы «Татэнерго» акционерлык җәмгыятенең Чаллы ТЭЦ филиалы өчен салкын суны транспортлаганга һәм җыентык суларны транспортлаганга 2017 елга календарь буенча бүленгән тарифлар

| № п/п | Муниципаль берәмлекнең, су белән тәэмин итүне һәм (яки) су бүлүне гамәлгә ашыручы оешманың аталышы | Салкын суны транспортлаган өчен тариф (бер ставкалы), сум/куб м. | | Җыентык суларны транспортлаган өчен тариф (бер ставкалы), сум/куб м. | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | Карар үз көченә кергән көннән башлап 2017 елның 30 июненә кадәр | 2017 елның 01 июленнән башлап 2017 елның 31 декабренә кадәр | Карар үз көченә кергән көннән башлап 2017 елның 30 июненә кадәр | 2017 елның 01 июленнән башлап 2017 елның 31 декабренә кадәр |
| | «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге | | | | |
| 1 | «Татэнерго» акционерлык җәмгыяте | | | | |
| 1.1 | «Татэнерго» акционерлык җәмгыятенең Чаллы ТЭЦ филиалы (тарифлар НДС исәпкә алмыйча күрсәтелде) | 0,61 | 0,61 | | |
| 1.1.1 | Технологик яктан үзара бәйләнмәгән берничә үзәкләштерелгән система булуга карап, тарифларны дифференциацияләштерү: | | | | |
| 1.1.1.1 | Сәнәгатьтәге җыентык суларны су бүлү | | | 1,11 | 1,11 |
| 1.1.1.2 | Явым-төшем җыентык суларын су бүлү | | | 1,14 | 1,14 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге